

Россиядә педагог һәм остаз елында нәтиҗәләрне Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбе, педагог-лар династиясе вәкиле, тәҗрибәле, хөрмәтле директоры Ирфан Касим улы Булатов житәкчелегендә лаеклы тәмамлаганнар. Шуларнын кайберләре турында.
- Безнен мәктәптә 37 укучы белем ала. Аларнын һәрберсе моһим һәм кыйммәтле, һәрберсе уникаль һәм vзенчәлекле сәләтләргә ия. Бу уку яртыеллыгында безнен укучылар торле конкурсларда, олимпиадаларда катнаштылар һәм тиешле урыннарны алдылар, - диелгән мәктәп сайтларында. - Болар барысы да педагог эшенен нәтижәләре һәм укучыларнын сәләте, тырышлыгы.      Барлык конкурслар һәм чаралар арасында, һәр мәктәп очен ин моһимнәре - предмет олимпиадалары булган һәм шулай булып кала да. Чонки бу укучыларнын белемнәрен лаеклы бәяләvнен ин яхшы ысулы; белем кимчелекләрен һәм кочле якларын ачыкларга ярдәм итә.
Татар Тавла авылындагы топ мәктәбе укучылары ел саен белем йортларын лаеклы тәкъдим итәләр һәм 2023 елда да шулай булган.
Нәтижәләрен сезнен белән уртаклашабыз.
Татар теле буенча республика олимпиадасынын муниципаль этабы жинvчеләре: 8 сыйныф укучысы Салькаева Сафина, 7 сыйныф укучысы Абузярова Зарина.
Татар әдәбияты буенча республика олимпиадасынын муниципаль этабы призерлары: 8 сыйныф укучысы Салькаева Сафина, 7 сыйныф укучысы Абузярова Зарина. Сәләтле укучыларны озак еллар тырышып Ана теленә мәхәббәт тәрбияләгән, татар теле һәм әдәбиятыбыз предметлары буенча нык-лы белем биргән укытучылары - Альфия Фатих кызы Муртазина.
Биология буенча Ботенроссия укучылар олимпиадасынын муниципаль этабы жинvчесе - 8 сыйныф укучысы Салькаева Сафина, ә муниципаль этабы призеры - 7 сыйныф укучысы Абузярова Зарина. Аларга бу предмет буенча ныклы белем биргән һәм ярышларга әзерләгән укытучылары - Диана Гафият кызы Абдуллова. Һәм шул ук укытучы география фәне буенча Ботенроссия укучылар олимпиадасынын муниципаль этабы призерын, 8 сыйныф укучысы Рызванов Айратны да әзерләгән.
Олы стажлы Гельнара Джумбай кызы Абдуллова рус әдәбияты буенча Ботенроссия укучылар олимпиа-дасынын муниципаль этабы призерын, 8 сыйныф укучысы Алмакаева Сабинаны әзерләгән.
Жәмгыять белеме буенча Ботен-россия укучылар олимпиадасынын муниципаль этабы призерын - 8 сыйныф укучысы Алмакаева Сабинаны ана-аталар, укучылар хөрмәтен яулаган белгеч - Рима Хәмзә кызы Рахмятуллова әзерләгән.



29 декабрьдә беренче яртыеллык йомгакларына, торле конкурсларда һәм олимпиадаларда жинvчеләрне һәм призерларны бvләкләvгә һәм булачак бәйрәмнәр

белән котлауга багышланган линейка узган. Мәктәп директоры, урынбасары белән бергә, 7нче сыйныф укучысы Абузярова Зарина Ләмберә муниципаль районында “Беренчеләр” хәрәкәте Гомумроссия ижтимагый - дәvләт балалар һәм яшьләр хәрәкәтенен жирле бvлеге эшчәнлегендә актив катнашканы очен Рәхмәт хаты, значок, блокнот һәм беренчеләр хәрәкәте логотибы белән футболка белән бvләкләнгән. Беренчеләрдән булып хәрәкәт эшчән-легендә актив катнашкан очен Рәхмәт хаты “Татар-Тавла топ гомуми белем бирv мәктәбе”нә дә тапшырылган.
Ә унынчы январьда Мордовиядә 2023-2024 уку елында Ботенроссия укучылар олимпиадасынын тобәк этабы башланды. Мордовия Республикасы мәгариф министры Елена Солдатова хәбәр иткәнчә, олимпиаданын респуб-лика этабында катнашу хокукына 3,5 меннән артык 9-11 сыйныфларда укучы ия булган.
Беренче булып француз теле буенча олимпиада старт алды, ә ярышлар эстафетасын тормыш иминлеге нигезләре буенча олимпиада тәмамлаячак. Мәктәп укучыларынын гомуми белем бирv фәннәре буенча Ботенроссия олимпиадасынын тобәк этабы 29 февральгә кадәр дәвам итәчәк.
Белешмә
Татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадаларнын регион этабы 15-16 январьда Н.П.Огарев исемендәге университет бинасында vтте. Анда муниципаль этапта жинvче 9-11 сыйныф укучылары катнашты.
Ә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы 2024 елнын 5-8 февралендә татар теле һәм әдәбияты буенча Тобәкара олимпиада vткәрә. Олимпиадада катнашу очен татар теле буенча олимпиаданын тобәк (олкә) турларында жинvчеләр арасыннан 8-11 сыйныф укучылары чакырыла.
Олимпиада 2 турдан торачак: язма тур - татар теле һәм татар әдәбияты буенча биремнәрне vтәv. Телдән тур - Гаилә елына багышланган нәфис сvз. Танылган татар язучылары һәм шагыйрьләре гаиләсе турында шигырь яки прозаны яттан уку кvздә тотыла.

**Наилә НАСЫРОВА**